**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 20 июнь № 449

г. Казань

Чаллы шәһәре «Махсус санитар автотранспорт предприятиесе» дәүләт унитар предприятиесен үзгәртеп оештыру турында

Татарстан Республикасында дәүләт автоном учреждениеләре белән идарә итүне оптимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Чаллы шәһәре «Махсус санитар автотранспорт предприятиесе» дәүләт унитар предприятиесен (алга таба – унитар предприятие) үзгәртеп кору юлы белән Чаллы шәһәре «Махсус санитар автотранспорт предприятиесе» дәүләт автоном учреждениесенә (алга таба – автоном учреждение) үзгәртеп оештыру турында тәкъдимнәрен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы автоном учреждениенең гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы булып тора, дип;

автоном учреждение тапшыру акты нигезендә үзгәртеп корылган унитар предприятиенең хокуклы дәвамчысы булып тора, дип;

автоном учреждение эшчәнлегенең төп максаты Чаллы шәһәренең сәламәтлек саклау учреждениеләрен транспорт белән тәэмин итү, дип;

оештыручының дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итү, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре һәм коммерциягә карамаган башка оешмалар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм аның үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2010 ел, 29 апрель, 308 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән раслана торган Татарстан Республикасы социаль хезмәтләр күрсәтү учреждениеләренең дәүләт

йөкләмәсеннән, финанс чыгымнары нормативларыннан һәм аларның мөлкәтен карап тоту нормативларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

2015 елның 15 июленә кадәр, гамәлдәге законнар нигезендә, унитар предприятиене үзгәртеп оештыруга бәйле чаралар үткәрергә, шул исәптән предприятие Уставына тиешле үзгәрешләрне кертергә һәм тапшыру актын расларга;

автоном учреждениене дәүләт теркәвенә алган көннән соң бер ай вакыт эчендә, учреждениегә оператив идарә итү хокукында Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәтен, шул исәптән предприятиегә хуҗалык алып бару хокукында элегрәк беркетелгән аеруча кыйммәтле күчмә мөлкәтне беркетергә;

автоном учреждениене дәүләт теркәвенә алган көннән соң бер ай вакыт эчендә күзәтү советы составын расларга;

ел саен автоном учреждение өчен дәүләт йөкләмәсен аның Уставы белән күздә тотылган төп эшчәнлек нигезендә расларга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\449.docx